КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 декабрь г.Казань № 1284

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2010 ел, 1 апрель, 216 нчы карарының белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 03 июль, 471 нче, 2017 ел, 22 декабрь, 1027 нче, 2018 ел, 27 июнь, 525 нче, 2018 ел, 24 октябрь, 946 нчы, 2022 ел, 25 май, 486 нчы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Балалар тормыш иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына, 1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы йөзендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлгә ашыра (алга таба - Гамәлгә куючы).».

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 ел, 27 февраль, 129 нчы карары белән расланган «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 10 октябрь, 901 нче, 2021 ел, 22 июль, 644 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы

министрлыгы йөзендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлгә ашыра (алга таба - Гамәлгә куючы).»;

5.2 пунктның 3 һәм 4 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.2[1] пункт өстәргә:

«5.2[1]. Учреждение җитәкчесен билгеләү (раслау), аның вәкаләтләрен туктату, аның белән хезмәт шартнамәсен төзү һәм туктату Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин